# КАРАР

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Красна торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

22 ноябрь 2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 22 ноябрендә 17.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, «2026 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красна авылында яшәүче 1 нче группа инвалид, 90 яшьтән өлкән гражданнардан тыш, җирле әһәмияттәге торак пунктта яшәүче гражданнарның яшәү урыны буенча даими яшәүче һәм даими яшәүче гаилә әгъзаларыннан 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү килешәсезме» һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, чүп-чарларны бетерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 30 (утыз) катнашучы, тавыш бирүдә 16 кеше катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны кертелгән, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 16 (уналты) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красна авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красна авылында яшәүче һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум (бер мең) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, чүп-чарларны бетерү.

2026 елда 1 төркем инвалидларын, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны үзара салым түләүдән тулаем азат итәргә. Барлыгы 2 (ике) кеше.

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтта бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Гатауллин